**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «2015 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының $28^2$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 2 апрелендәге ПУ-168 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «2015 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы ПУ-20 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бөрмәнчек» дәүләт керәшен фольклор ансамбле.»;

б) 2 пунктта «241 307,2» саннарын «243 908,4» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указда каралган чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2015 ел, 23 март
№ ПУ-303